ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НАЛАСИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.М.Вахитова, д. 64, с.Наласа,
Арский муниципальный район, 422018

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
НАЛАСА
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
М.Вахитов урамы, 64 йорт, Наласа авылы,
Арча муниципаль районы, 422018

Тел. (84366)50-2-25, факс (84366)50-2-25. E-mail: Nalas.Ars@tatar.ru

# КАРАР

« 30 » гыйнвар 2023 ел №  1

**«Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «авыл җирлеге » муниципаль берәмлегенең салым чыгымнары исемлеген формалаштыру тәртибен раслау турында» Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Наласа авыл җирлеге башкарма комитетының 2021 елның 28 апрелендәге 11 номерлы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында**

«Россия Федерациясе субъектлары һәм муниципаль берәмлекләрнең салым чыгымнарын бәяләүгә гомуми таләпләргә үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 15 июнендәге 1081 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары нигезендә Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Наласа авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Арча муниципаль районы Наласа авыл җирлеге башкарма комитетының 28.04.2021 ел, № 11 карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) 3 пунктта «муниципаль программаларның структур элементларын» сүзләрен төшереп калдырырга;

б) икенче абзацтагы 12 пунктта «муниципаль программаларның структур элементларына» сүзләрен төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan/ru) бастырып чыгарырга һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында (http://arsk.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

**Наласа авыл җирлеге**
**Башлыгы:** **И.Р.Шакирова**